Хәзер алар инде түләнгән товарны китерү турында хәбәр итәләр һәм алуны раслауны сорыйлар. Ялганны ничек танырга? Беренчедән, мошенниклар янәсе маркетплейс яки анын курьерлары исеменнән шалтыраталар һәм инде түләнгән товарны китерергә тәкъдим итәләр. Әгәр дә кеше бернәрсә дә сатып алмадым дип каршы килә икән, жинаятьчеләр, могаен, танышларыннан берәрсе бу заказны бүләккә рәсмиләштергән, -ди-бернинди хата да булырга момкин түгел. Ышандырырлык булсын очен кешегә хәтта анын шәхси мәгълүматларын: фамилиясен, исемен һәм атасынын исемен, шулай ук китерү адресын да атарга момкиннәр. Бу теркәлү, яшәү яки эшләү урыны булырга момкин.

Аннары, янәсе, заказны тапшыру датасын һәм урынын раслау очен, жинаятьчеләр сойләшү вакытында килгән смс яки пуш-хәбәрнамәдән кодны атауны сорый. Әмма чынлыкта бу вакытта телефонга банктан бер тапкыр кулланыла торган пароль килә. Анын ярдәмендә мошенниклар интернет-банкка керергә һәм кеше счетыннан акча урларга момкин.

Сезгә мондый тәкъдим белән шалтыратсалар, нишләргә? Трубканы куегыз. Шалтыратучы кеше кем генә булып күренмәсен һәм ул хәбәрнен цифрларын нинди генә сылтау белән белергә тырышмасын, смс яки пуштан кодларны беркемгә дә һәм беркайчан да хәбәр итмәгез. Маркетплейсларнын чын хезмәткәрләре беркайчан да паспорт мәгълүматларын, смс кодларын һәм банк картасы мәгълүматларын атауны сорамый.

Мошенниклар тарафыннан алдау-алдану очраклары турында кон дә ишетелеп торган хәбәрләр күпләргә сабак булган, ахрысы. Бүген илдә интернеттан файдаланучыларнын барысы да диярлек (97 процент) ничек тә шәхси мәгълүматларын саклау ягын карый. Күптән түгел ВЦИОМ - Илкүләм халык фикерен ойрәнү үзәге белгечләре тарафыннан уздырылган сонгы сораштыру нәтижәләре шул хакта сойли. Респондентларнын 72 проценты шәхси логин-парольләрен беркайчан да телефоннан яки электрон почта аша СМС рәвешендә башка кешегә жибәрми икән. Сораштыруда катнашучыларнын тагын бер ише (71 процент) банк картасы турындагы мәгълүматларны теләсә кайда сакламавын, антивирус программасы куллануын (62 процент), социаль челтәрләргә үзе турында шәхси мәгълүмат урнаштырмавын (62 процент) әйткән. Респондентларнын 44 проценты, мошенник тозагына эләкмәс очен, сәүдә үзәкләрендәге бушлай вай-фай хезмәтеннән дә файдаланмаска кирәк, дип саный. Тикшеренү барышында белгечләр интернет киңлекләрдә саклык мәсьәләсендә яшь буыннын күпкә анлырак булуын да ачыклаган. Ә менә пенсионерлар, зур булмаган шәһәр һәм авылларда яшәүчеләр, киберкурыныч сызлык турында яналыклар белән танышып бармаучылар ул яктан шактый калыша. Ә мошенникларнын алдау ысуллары коннән-кон янара бара.